Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Яңа Кәшер авыл Башкарма комитеты

КАРАР

08 апрель 2026 ел № 3

Әлмәт муниципаль районы Яңа Кәшер авыл Башкарма комитетының аерым карарларының үз көчләрен югалтуын тану турында

Россия Федерациясе Хезмәт кодексы нигезендә, хокукый мониторинг нәтиҗәләре буенча

Яңа Кәшер авыл башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Яңа Кәшер авыл Башкарма комитетының карарларының үз көчләрен югалтуын танырга:

- 2015 елның 20 ноябрендәге 17 номерлы «Муниципаль учреждение җитәкчесе, шулай ук муниципаль учреждение җитәкчесе вазыйфасына эшкә керүче зат тарафыннан үз керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында һәм үз иренең (хатынының) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү Кагыйдәләре хакында»;

- 2020 елның 14 маендагы 3 номерлы Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы авыл башкарма комитетының 2015 елның 20 ноябрендәге 17 номерлы «Муниципаль учреждение җитәкчесе, шулай ук муниципаль учреждение җитәкчесе вазыйфасына эшкә керүче зат тарафыннан үз керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында һәм хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү Кагыйдәләре хакында» карарга үзгәрешләр кертү турында»;

2. Әлеге карарны торак пункт территориясендә Әлмәт районы, Яңа Кәшер авылы, Тавабилов урамы, 153 йорт, Бикасаз авылы, Мәктәп урамы, 1А йорт, территориясендә урнашкан махсус стендларда игълан итәргә, шулай ук «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Яңа Кәшер авыл башкарма комитеты җитәкчесе А.Ш. Садриев